
2/90

Апрель

Салават күпере





Карга боткасы

Борын-борын заманда кешеләр ни өчен яз булганын белмәгәннәр, ди. Алар ямьле язны җылы яклардан кара каргалар алып килә икән дип уйлаганнар. Шуның өчен карлар эреп, сулар ага башлагач, каргалар килү хөрмәтенә бәйрәм ясый торган булганнар. Аны «Карга боткасы» дип атаганнар. Бәйрәм көнне авыл балалары кулларын, карга канатын каккан шикелле җилпеп, урам буенча чабып, халыкны бәйрәмгә чакырып йөргәннәр:

Карга әйтә: кар, кар,
Туем җитте, бар, бар!
Ярма, күкәй алып бар,
Сөт-маеңны алып бар,
Ипи-итең алып бар,
Карр, карр, карр!

Шуннан соң барлык балалар, азык-төлекләр алып, су буйларына яки тау битләренә җыелганнар. Анда казан асып, ботка пешергәннәр, уеннар уйнаганнар, җырлар җырлаганнар, биюләр биегәннәр. Бәйрәм бергәләшеп ботка ашау белән тәмам булган. Ләкин балалар ботканы үзләре генә ашап бетермәгән, өйләренә кайтып киткәндә: «Рәхмәт, кошкайларым, безгә язны алып килдегез!» — дип, боткаларын каргаларга калдырып китә торган булганнар.

Каргалар, балалар кайтып киткәч:
— Кар, кар,
Әйбәт дуслар бар, бар,—
дип, нәниләргә рәхмәт укый-укый, тәмле ботканы чукыганнар.

Рәшит ЯГЪФӘРОВ.



Карга боткасына сый җыйганда

Өйдәме, түтәй?
Җәтрәк бир күкәй.
Бирсәң безгә өч күкәй,
Тавыгың салыр йөз күкәй.
Май кирәк, ярма кирәк,
Карга туена бар да кирәк.
Тагын булса он чыгар,
Пешерербез без чумар.
Шикәр кирәк, тоз кирәк,
Чыгар, түтәй, тизрәк!
Синең кебек уңган түтәй
Бу дөньяда бик сирәк.

Саналыш

Карга килер — казан асар,
Торна килер — тоз салыр,
Саескан килер — салма
салыр,
Песнәк килер — пешерер,
Чыпчык килер — төшерер,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Кечкенә түти туймый калыр,
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимерер...

Әйдәгез, уйныйбыз!

БУЯУ САТЫШ

Балалар, бер рәт хасил итеп, тезелешеп утыралар. Арадан берсе буяу сатучы, берсе буяу алучы була. Буяу алучыны икенче бүлмәгә чыгарып җибәрәләр дә, буяу сатучы аңа ишеттермичә генә, монда калганнарга төрле буяу исемнәре кушып чыга (ак, кызыл, яшел, көрән һ. б.).Шуннан алучы «ишек кагып керә»:

— Дөбер, дөбер!
— Кем бар?
— Олаучы бар.
— Ни кирәк?
— Җеп мандырам, буяу кирәк.
— Нинди?
— Сары (яки нинди дә булса башка төсне әйтә).

Сары дигән буяу тора да йөгерә башлый. Алучы тота алса, аның урынына утыра. Тота алмаса, яңадан буяу ала. Сары буяуга яңа исем кушалар.

Рәссам Й. ВӘЛИӘХМӘТОВ

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ
(Мәсәлләр)

ӘТӘЧ ИЛӘ КҮКЕ

— И сөекле әтәч, нинди матур сайрыйсың!

— Ә син, күкеҗан, бигрәк моңлы, бигрәк күңелле җырлыйсың! Синдәй сайраучы бөтен дөнья урманнарында да булмас. Аһ! Синең җырлавыңны үлгәнче тыңлап кына торыр идем. Менә, билләһи, ант итәм. Әгәр син сайраудан туктасаң, тагы кайчан гына сайрый башлар икән дип көтәмен. Минемчә, синең тавышың янында сандугач тавышы бөтенләй югаладыр; белмим, оҗмах кошлары сиңа пар була алырлар микән?..

Бу макташуны читтән тыңлап торган чыпчык, әтәчнең сүзен бүлеп:

— Сез, дуслар, бер-берегезне макташып киерелсәгез дә, музыкагыз һаман борынгыдыр,— диде.





МАКТАНЧЫК КУЯН

Ерткучы хайваннар, бергәләшеп, бер зур аюны аулап ектылар.

Табышны уртага салып, үзара бүләргә тотынганда, бер яктан куян да килеп, аюның бер колагына ябышты.

Башка ерткучы хайваннар куянның болай батырчылык иткәненә гаҗәпләнеп һәм ачуланып: «Әй син, Кыек аяк! Син нигә тотынасың? Аюны аулаган вакытта синең эзең дә күренмәде бит!» — дип кычкыргач, куян бер дә аптырамыйча:

«Ә аюны урманнан кем куып чыгарды дип беләсез?» — диде.

Куянның бу мактануы ерткучыларга бик кызык вә көлке күренгәнлектән, аңар дәгъвасы буенча аю колагын тапшырдылар.

* * *

Мактанчыклардан гәрчә көлсәләр дә, күп вакытта аларга да өлеш тиядер.



КӨЗГЕ ҺӘМ МАЙМЫЛ

Маймыл көзгедән үзенең сурәтен күргәч әкрен генә янындагы аюга аягы белән төртеп:

«Кара әле, иптәш! Көзгедә кыяфәтсез, нинди ямьсез хайван күренә. Кара әле, аяклары нинди кәкре, кара әле, йөзе нинди килешсез! Әгәр мин шул көзгедә күренгән нәрсәгә аз гына охшасам да, хәсрәтемнән буылып үләр идем.

Хәер, әйтергә мөмкин, минем иптәш вә дусларым арасында да бу көзгедә күренгән хайван төсле ямьсезләр биш-алтылап бар, хәтта мин аларны бармак белән санап күрсәтә алам»,— диде.

Аю моңар җавапта:

«И маймыл иптәш! Син, иптәш вә дусларыңны санап мәшәкатьләнгәнче, бер мәртәбә үзеңә генә карасаң булмасмы?» — диде.

ЕЛАН ИЛӘ БӘРӘН

Кое янында бер елан бөтен дөньяга каршы зәһәрләнеп, ачуланып ята иде.

Еланның ачулану өчен генә яратылган һәм зәһәрләнү хисеннән башка хисе юк икәне билгеледер.

Шуннан ерак түгел бер җирдә кечкенә генә яшь бер бәрән, еланның барлыгыннан да хәбәре булмыйча, йөгереп, рәхәтләнеп уйнап йөри иде.

Менә бервакыт елан, бәрәнгә таба әйләнеп, авызыннан угын чыгарып, күзләре алдында һава томанланып, бөтен каны кайнап, кәһәрләнә башлады.

Еланның кыланышларыннан гаҗәпләнгән бәрән, аның янына ук килеп: «И елан! Соң бу кадәр ачуланырлык мин сиңа ни зарар китердем?» — дигәч, елан:

«Кем белсен? Бәлки, син мине таптар өчен шулай сикергәләп йөри торгансың»,— диде.

* * *

Кемнең ки күңеле дуслык, сөешү кеби хисләрдән буш яратылган булса, аның каршында бөтен халык дошмандыр.

Рәссам Ш. НАСЫЙРОВ



Бари РӘХМӘТ

МАЙ АЕ

Майдан да ямьле ай,
Җанлы ай юк бугай,
Беренче Май белән
Башлана шул бу ай.

һәр агач, һәр үлән
Чәчәккә күмелгән.
Әйтерсең, аларга
Ислемай түгелгән.

Аларның хуш исен
Киң сулап иснисең,
Бәйрәме дә майның
Күңелле ич дисең.

БЕРЕНЧЕ МАЙ БӘЙРӘМЕ

Гөлләр, чәчәкләр тотып,
Тәмле исләр аңкытып
Тагын килеп җитте Май —
Сагынып көтеп алган ай.

Бүген бәйрәм булганга,
Бик күңелле урамда.
Күңелле шул бу бәйрәм,
Гөрләп тора зур мәйдан.

Бәйрәмгә дип әниләр
Пешергәннәр мәмиләр:
Өстәл тулы паштетлар,
Прәннекләр, конфетлар,
Кабартмалар, коймаклар,
Атланмайлар, каймаклар.

Разил ВӘЛИЕВ

МАЙ КОЯШЫ

Май кояшы күктән көлеп карый,
Май кояшы нигә сөенгән?!
Агачлар да бәйрәм көткән кебек
Яшел киеменә киенгән.

Июнь булып, хәтта июнь ае
Май аена карап көнләшә.
...Май кояшы, һәр өй саен кереп
Кешеләргә шатлык өләшә.

Нурия ИЗМАЙЛОВА

МЕНӘ НИНДИ ИКӘН ЯЗ!

Бар җир чәчкә, гөл генә,
Кояш елмая, көлә —
Менә нинди икән яз!

Өскә башка кимисең,
Өшемисең, туңмыйсың —
Менә нинди икән яз!

Җиргә ятып ауныйсың,
Көлеп туя алмыйсың —
Менә нинди икән яз!

Мәрзия ФӘЙЗУЛЛИНА

ЯЗ БӘЙРӘМЕ

— Шомырт, кемне яраттың,
Кем өчен чәчкә аттың?
— Ямьле язгы ай өчен,
Яз бәйрәме — Май өчен!

— Бик матур итеп шулай,
Ник җырлыйсың син, тургай?
— Олылап язгы айны,
Котлап Беренче Майны!



Рәссам З. МӨХӘММӘТҖАНОВА

БАТУЛЛА

МЫРЫЙ БЕЛӘН УРМАН ТЫЧКАНЫ

Ата мәче Мырый:

— Берәр тычкан баласы тотып ашап булмасмы? — дип урманга таба киткән, ди.

Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына, диләр. Дөрестер. Мырый каршысында бер урман тычканы очраган.

— Тукта! — дигән аңа ата мәче.— Мин сине ашыйм.

Тычкан барган җиреннән туктап кала.

— Син мине ашый алмыйсың, Мырый! — ди Тычкан.

— Ник? Нигә? Ничек инде? Гомер-гомергә мәчеләр тычканнарны ашаганнар! — дигән Мырый.

— Гомер-гомергә шулай булган шул! — дигән Тычкан.— Син ата мәче Мырый басу-кырым тычканнарын ашадың, казан тирәсендәге тычканнарны ашадың, инде хәзер урман тычканнарын да ашап бетерергәме исәбең? Булмас!

Шулай дигән дә урман тычканы ата мәче Мырыйны тотып ашаган, ди.

ШҮРӘЛЕ КУНАК ҖЫЯ

(Әкият)

Рәссам Ф. МУЛЛАХМӘТОВ

Борын-борын заманда ук, әле син дә, мин дә булмаган чакларда, Шүрәле абзый мәҗлес җыйган ди. Мәҗлескә күп кенә җанвар-киекләр чакырылган, ди. Ләкин бер шарт белән: һәрберсе табынга яраткан ризыгын үзе алып килергә тиеш булган. Шуннан соң мәҗлескә килергә теләге булганнар яраткан ризыкларын эзләргә чыгып киткән, ди...

Боларның кайсы кая таба барачак! Әкиятне дәвам иттер.



Кол Гали

Йосыф китабы

И. Әхмәдиев рәсемнәре

Мисыр сәүдәгәре Малик бине Дугыр гаҗәп бер төш күрде һәм юраучыга сөйләде:

«...Гъәд коесы тирәсендә йөргән идем,
Кояш шунда Күктән җиргә иңде инде...»

Юраучы әйтте:

«...Гъәд коесы тирәсендә йөрдең исә,
Бер затлы кол кулларыңа керер инде...»

Малик Дугыр кәрваны коега килде һәм аннан Йосыфны тартып алдылар.





Йосыфның кардәшләре моны белде һәм Маликтан: бу безнең качкан кол, дип, энеләрен дәгъвәләделәр. Аннары үзара килештеләр дә Йосыфны Малик сәүдәгәрнең үзенә үк сатып та җибәрделәр.



Зөләйха Йосыфны Мисыр шаһы дип уйлады һәм этисенә әйтте:

«Теләгәнем — Мисыр шаһы».

Этисе фатыйхасын һәм күп байлыклар биреп кызын Мисыр шаһына җибәрде. Зөләйха ялгышты: ул чакта Мисырда шаһ Кыйтфир иде. Зөләйха Кыйтфир хатыны булды.

Мәгъриб илендә Зөләйха атлы бик чибәр, тулган айдай йөзле, оҗмахтагы хур кызыдай гүзәл яши иде. Беркөнне Зөләйха Йосыфның сурәтен төштә күрде.

«...Күрү белән шундук аңа гашыйк булды,
Уянды да елый-елый килә инде...»
«Зөләйхабыз йокысыннан мәхрүм калды,
Ай шикелле күркәм йөзе тәмам сулды,




Төне-көне гел Йосыфны уйлый инде.»



«Болардан соң җиде ел җил кебек очты,
Күп хәл үтте, күпме айлар килде, кичте,
Яшь Йосыф та шул Мисырга килеп төште,
Мисырда ул кол буларак сатыла инде».
Зөләйха Йосыфны күрде һәм әйтте:
«...Минем өчен аны сатып алыгыз сез,
Бар малымны шуңа сарыф кылыгыз сез»...
Мисыр шаһы кол Йосыфны Малик Дугырдан сатып алды.

Йосыф белән аулакта күрешеп, гыйшкын аңлатыр өчен Зөләйха бик зиннәтле сарай салдырды һәм Йосыфны анда чакыртты да әйтте:
«...Мин бит сине төштә күрдем,
Шуннан бирле сурәтеңә гашыйк булдым...»
Йосыф аның мәхәббәтен кире какты, мин кол, син минем хуҗамның хатыны, диде.





Мисырдагы хатын-кызлар үз колына гашыйк булган Зөләйхадан бик көлделәр. Зөләйха аларны акылга утыртырга уйлады. Һәммәсен дә сарайга кунакка чакырды, җимеш өләште һәм кулларына пычак тоттырды. Аннары бүлмәгә матур киенгән Йосыфны кертте. Колның матурлыгына таң калган хатыннар җимеш урынына пычак белән бармакларын турый башладылар.

...Ә соңыннан Зөләйханың гыйшкын кире каккан кол Йосыфны зинданга ташладылар.


Таң ату

Нур укларын атты Кояш
офык-ярдан — Күк йөзенә!
Качты Төн — ябалак күзенә!

Равил ФӘЙЗУЛЛИН

Бабай таягы

Бабай таягына чыпчыклар куна,
Бабай таягында эшләпә тора.
Бабай таягында сөялле куллар,
Бабай таягына озак еллар...



Марсель ГАЛИЕВ

Тамаша

Әтәч койрыклы кәҗә
сакалын җирдән сөйри.
Сакалга басмас өчен
артка чигенеп йөри.
Алты мөгезле сыер
аклы-каралы туннан.
һәр мөгезнең иң очына
берәр сыерчык кунган.
Кара күзлекле Муйнак
китап тоткан, күр, әнә!
Мәчене куркытырга
өру фәнен өйрәнә.
Өй кыегында кояш
авыз кыйшайтып көлә.
Кармак тотып түбәгә
сак мәче менеп килә.
«Бу ни тамаша!» — диеп,
кызыксынсаң син әгәр,
минем рәссам энекәш:
«Була,— дип,— шундый хәлләр,—
альбомын ачып ташлар,—
мин шулай күрәм»,— диеп,
кызып аңлата башлар.

Рәссам А. ТИМЕРГАЛИНА



Сафа Гыйльфан

Уф, ардык





Йөгердек,
Сикердек,
Уйнадык,
Бакчада
Саф һава
Суладык,
Уф, ардык!

Җырладык,
Биедек,
Куандык,
Хәрефләр
Тезгәләп
Юандык,
Уф, ардык!

Шакмаклар,
Тартмалар
Өйгәләп,
Биналар
Ясадык
Бергәләп,
Уф, ардык!

Ашадык
Тәмле аш,
Күмәчләр,
Чәй эчтек
Шикәрләп
һәм сөтләп,
Уф, ардык!

Өч сәгать
Шауладык,
Гөж иттек,
Инде ял
Сәгате дә
Җитте,
Уф, ардык!

Ял өчен
Бер сәгать
Күп вакыт,
Әйдәгез,
Сөйләшми
Тын ятыйк!
Уф, ардык!

Без тагын
Торгачтын
Уйнарбыз,
Бакчада
Саф һава
Суларбыз,
Уф, ардык!

Ә хәзер
Әйдәгез,
Тиз тыныйк,
Йокыга
Китәбез,
Күз йомыйк,
Уф, ардык!



Рәссам З. ХӘКИМОВ

Фоат САДРИЕВ

КЫЗЫКЛЫ КӨН



(Әкият-шаяру)

Ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз юк, мин бу хәлләрне бер көн эчендә үз күзләрем белән күрдем. Иртән торсам, бакчада җиләкләр ята пешеп, күктән кар ява ишеп. Утырып коймак ашагач, чуар тавыкка яшел үлән ташлагач, киттем, малай, кармак салырга сөт елгасы ярына. Балакларны тезгә кадәр сызгандым, кармак колгасын кулыма алдым, бүрек колакчынын бәйләдем, барам шулай тездән кар ерып. Күктә кояш пешерә, җирдә буран котыра, кармак колгасында сандугачлар җырлап утыра.

Җиде көн, җиде төн бертуктаусыз йөгереп, барып чыктым бер диңгезгә — чын дөресен сөйлим мин сезгә. Килеп кердем чабып, чак китмәдем авып: аяклар күп йөгерүдән шул кадәр кызган, китереп басуга су парга әйләнә чыжлап. Диңгез тирән, мин һаман эчкәрәк керәм.

Диңгез ярып шактый баргач, каршыма килеп чыкты бер алмагач. Кулымнан эләктереп алды да уңга таба сөйрәде, үзе әкиятләр сөйләде. Килеп җиттек бер утрауга. Алмагач шундук тамырлары белән җиргә кереп утырды, алма белән җирне тутырды. Ачыкканмын икән — аларны ашап бетердем, ботакта калганнарын да авызга коеп төшердем. Алмаларның төшләре корычтан, барыбер ашадым бер очтан. Яфраклары тимердән, аларын кәҗә мәлгунь кимергән.

Чаңгы тотып утрау эченәрәк киттем, бер урынга барып җиттем. Монда, малай, хикмәт икән, һәркемнең башында кисмәк икән. Мәче белән тычкан кочаклашып җырлап киләләр, очраганнарга шартлатып тибәләр. Мәченең күзләре экран булып яна, икесендә ике программа тапшыруы бара. Бүре белән куян яталар муенга муен.

Шигырь укый тавык, гармун уйный карт сарык, суалчан киткән авып. Кыяр йомырка салып маташа, карап торсаң, үзе бер тамаша. Таракан чәчкән тары, кабакка әйләнгән бары.

Диңгез эченә күкрәктән кереп кармак сала яшь табыклар, тегермәнгә капчык-капчык хәреф төяп килгән балыклар. Мөшкәгә хәреф салалар — сүз булып чыга, сүзне казанда кайнаталар — җөмлә пешә.

Бер малай альбомына ясаган эт белән мәче рәсеме — тегеләр шунда сугышып китмәсенме?! Альбомны ерткалап бетергәннәр, өйдәге савыт-сабаны кырганнар, соңыннан тегенең фломастерын алып сызганнар.

Галәмәт монда хәлләр, кем кемне җәлләр!

Карап-карап йөрдем дә өйгә элдердем. Күргәннәремне тизрәк сезгә сөйлим дидем. Әле бу башы гына, йөзекнең кашы гына. Күргәннәремнең калганын озаклап сөйләрмен, тыңларсың, түзәрсең, унбиш тиен түләрсең.

Ант итәм ата мәченең күзе белән, чырайсыз үгезнең мөгезе белән, эт малаеның сүзе белән, әбиемнең күлмәклек бүзе белән: бу кызыклы көнне син үзең дә күрә аласың, әгәр белсәң чамасын.

Бүген беренче апрель, ник сөйләгәнемне үзең бел.

Рәссам З. МӨХӘММӘТҖАНОВА



ТАБИГАТЬТӘ КУНАКТА



КЫР БИЛЧӘНЕ (Бодяк полевой)

**Миңа КЫР БИЛЧӘНЕ диләр,
Чүп үләне дип йөртәләр.
Тик белмиләр, мин бик тәмле
Ашка салып пешерсәләр.**

КЫР БИЛЧӘНЕн кайбер төбәкләрдә каты каклавыч, кыр каклавычы, каты билчән дип тә атап йөртәләр. Ул июнь — сентябрь айларында чәчәк ата. Аның яшь сабагы һәм яфракларыннан салат ясыйлар, яшелчә ашы пешерәләр.

Билчәннән әзерләнгән төнәтмә тире авыруларын дәвалаганда файдаланыла.

Билчән яшелчә басуларында, кырларда, юл буйларында үсә. Эшкәртелгән туфракта тиз үрчи.



ТУКРАНБАШ (Клевер луговой)

**ТУКРАНБАШ дисәләр дә,
Мин тукранга охшамаган.
Мин бик татлы. Минем тәмне
Белми тик бал ашамаган.**

ТУКРАНБАШның чәчәге һәм өске яфраклары — дару өчен чимал. Йөткергәндә, ютәлләгәндә, бронхиаль астма вакытында чәй итеп яисә төнәтмә итеп кулланалар. Парландырылган чәчәген чуан өстенә һәм пешкән урыннарга ябалар.

Тукранбаш урман буйларында, болыннарда һәм куак араларында үсә. Еш кына махсус чәчеп үстерәләр.

МӘЧЕ БОРЧАГЫ

(Просвирник приземистый)

**Мин дә тәмле. Мине хәтта
Бик ярата песиләр.
Шуңа күрә исемемне
МӘЧЕ БОРЧАГЫ диләр.**

Әби күмәч, әби борчак, дуңгыз борчагы, мәче табаны дигән исемнәре дә бар.


Сәлперәйгән тәнле яисә юан кешеләргә ябыгу максатыннан үсемлек тамырын пешереп, шуның шулпасын эчәргә киңәш ителәэ.

Тамак төбе ялкынсынганда мәче борчагы яфракларыннан әзерләнгән төнәтмә белән авыз чайкыйлар. Яшь яфракларын төеп яисә пешереп сызлавыкларны, сөялләрне дәвалыйлар.

Мәче борчагын Мисырда һәм Кытайда махсус чәчеп үстерәләр.



Рәссам Ю. ДЕНИСОВ



БОЛГАРЛАР

Рәссам В. БУЛАТОВ

Айрат идәндә мавыгып уйный.

— Улым, җыеп куй әле шул уенчыкларыңны бер күчкә,— диде әтисе.

Айрат уйланып торды.

— Әти, нәрсә ул «күчкә»? — дип сорады. Ул йөргән бакчада татарча сөйләшмиләр, шуңа малай кайбер сүзләрне белми әле.

Әтисе кулындагы газетасын өстәлгә куйды да Айрат янына идәнгә чүгәләде.

— Әйдә җыйыйк әле уенчыкларыңны,— дип, аларны күчкә җыя башлады. Әшен бетергәч, әлеге күчкә төртеп күрсәтте: — Менә шушы була инде «күч».

— Ә-ә,— диде малай.

— Беләсең килсә, улым, «күч» сүзеннән башка сүзләр дә ясап була.

— Ничек?

Әтисе уенчыклар арасыннан мәче алды да: — Менә моны тегендәрәк күчереп куйсаң, яңа сүз килә дә чыга,— дип, малайга серле итеп карады.

— Нинди сүз? — диде Айрат.

— «Күчерү» сүзе. Ул да «күч» сүзеннән ясалган.

Айратка бу уен кызык тоелды. Ул:

— Тагын ясыйк,— диде.

— Син кошларның көз көне җылы якларга күчеп китүен беләсең инде. Шулай бит, улым? — диде әтисе.

Айрат баш какты. Аларга бу хакта бакчада тәрбияче апалары сөйләгән иде.

— Белсәң, шул: алар «күчмә кошлар» дип атала.— Әтисе елмаеп куйды.— Күрдеңме, без синең белән тагын бер сүз ясадык. «Күч-мә».

— «Күч-мә»,— диде Айрат. Аның бу сүзне отып каласы килде.

Әтисе аңлатуын дәвам итте:

— Бик-бик борын заманда безнең болгар бабаларыбыз да, кошлар кебек, бер урыннан икенче урынга күчеп йөргәннәр. Ул чакта алар әле киң далаларда яшәгән, бик күп сарык, сыер, ат көтүләре тотканнар. Ашаган-эчкәннәре ит һәм сөт булган. Бия сөтеннән кымыз ачытканнар, шуны эчкәннәр. Кымыз бик файдалы, шифалы эчемлек ул...

Шул чак Айрат:


— Алар нигә күчкән? — дип сорады.

— Мал-туарлар үләннәрне ашап бетергәч, болгарлар үләнлерәк яңа җиргә күчеп утыра торган булганнар. Анда да беткәч, тагын күчкәннәр. Шуңа аларны «күчмәләр» дип йөрткәннәр. Ул заманда безнең болгар бабаларыбыз Кара диңгез, Кавказ буе далаларында көн күргән. Соңыннан гына Татарстан җирләренә, Идел-Кама буйларына күчеп килгәннәр.

Айрат әтисен кызыксынып тыңлады.

— Белдеңме инде бабаларыңның кем икәнен? — диде әтисе.

— Бол...гар...лар...— диде Айрат һәм сөенеп янә кабатлады.— Болгарлар!



Көн җылынды

Мәхмүт Хәсәнов

хикәя

Әтисе белән әнисе һәйбәтләп киендереп Хәйдәрне дә үзләре белән ишек алдына алып чыктылар. Тышта салкын. Кар ява.

Әтисе белән әнисе утын кисәргә кереште. Ә Хәйдәр бер читкә басып карап торды. Бераздан аның бүрек түбәсен, җилкәләрен кар каплап китте.

Әтисе Хәйдәргә таба борылды да, елмаеп:

— Улым, кар күмеп китә күрмәсен үзеңне,— диде.

Ә бераздан әнисе:

— Улым, туңмыйсыңмы? — дип сорап куйды.

Хәйдәр ни диярга дә белмәде. «Туңам» дисә, өйгә кертеп җибәрүләре бар, ә аның өйдә утырасы килми. «Туңмыйм» дияр иде, суык. Әнә бит суык, шаярган кебек кенә итеп, борынны, бит очларын чеметеп алды. Аннары бияләй эчендәге бармакларга, итекләр эчендәге тәпиләргә үк барып җитте...

Әтисе белән әнисе эшлиләр дә эшлиләр. Кая ул туңу! Тирләп чыкканнар. Бераздан әтисе Хәйдәр янына килде.

— Улым,туңасың ич,— диде ул.—Яле, шушыларны утынлыкка илтеп куй, суык синең янда тора алмасын.

Хәйдәр ярып ташлаган утын агачларын берәм-берәм утынлыкка ташый башлады.

— Менә, улыбыз да эшкә ярый хәзер,— дип куаныштылар әтисе белән әнисе.

Бераздан Хәйдәр, әнисе янына килеп, бүрек колакчыннарын чишәргә кушты.

— Әни, көн җылынды! — диде ул.

Әтисе белән әнисе рәхәтләнеп көлештеләр. Аннары әтисе, Хәйдәрнең аркасыннан сөеп:

— Көн җылынмады, улым, эш җылытты сине,— диде.

Рәссам Е. ХИТРОВА

Әниләргә һәм нәниләргә

Муса ҖӘЛИЛ

БИШЕК ҖЫРЫ

Шаян кызым син минем,
Таң йолдызым син минем,
Йөрәгемдә кабынган
Шатлык җырым син
минем.

Синең гомерең җыр
булып
Яңрар бәхет илендә,
Йолдыз булып янарсың
Син туган ил күгендә.

Таңнан торып, бакчада
Син уйнадың көнозын.
Аргансыңдыр, кил,
кызым,
Йокла инде, йолдызым!

Әлли-бәлли-бәлли-бәү!
Әлли-бәлли-бәлли-бәү!

Рәссам А. ҮТӘГӘНОВ

Сәләвәт күпере

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ һӘМ ВЛКСМның ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА КОМИТЕТЫНЫҢ НӘНИЛӘР ӨЧЕН АЙЛЫК ЖУРНАЛЫ 1990 ЕЛНЫҢ МАРТ АЕННАН ЧЫГА

БАШ МӨХӘРРИР
Зиннур ХӨСНИЯР

ИДАРӘ

Шәүкәт ГАЛИЕВ,
Рафис КОРБАНОВ
(җаваплы сәркатип),
Ләбиб ЛЕРОН
(бүлек мөхәррире),
Роберт МИҢНУЛЛИН,
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ,
Солтан СӘЛИМҖАНОВ,
Мәгъсум ХУҖИН,
Фәридә ХӘСЬЯНОВА,
Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА,
Асия ЯРУЛЛИНА

Бизәлеш мөхәррире
Айдар ҮТӘГӘНОВ

Тышлыкның беренче
битендә
Ф. ЯКУПОВ рәсеме

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты
Казан, Декабристлар урамы, 2.

«Салават күпере» ежемесячный журнал Правления Союза писателей ТАССР и Татарского РК ВЛКСМ для малышей. Издается при участии Советско-Финской фирмы «ПОИНТ» (на татарском языке). Основан в 1990 году.

Адрес редакции: 420012, г. Казань, ул. Комлева, 14. Редакция журнала «Салават күпере».

Производствога бирелде 2.02.90 ел. Басарга кул куелды 15.03.90 ел. Кәгазь форматы $84 \times 108^1/_{16}$. Басма табак 1,0 (2,1). Офсет ысулы белән басыла. Тиражы 25 мең данә. Зак Д-58. Бәясе 50 тиен.



КҮЧМӘ КОШЛАР

Зәки НУРИ

КОШЛАР КАЙТА





Ачылды ак калын юрган,
Исте апрель җилләре.
Кошлар кайта: сагындырган
Туган-үскән җирләре.

Көннәрен юлда үткәреп
Куанышып очалар,
Канатларына күтәреп
Яз китерә ич алар.







Рәссам И. ВӘЛИӘХМӘТОВ

Рәсемдә сурәтләнгән кошларның исемнәрен әйтегез?

Бәясе 50 тиен.